КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 16 сентябрь г.Казань № 838

Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру чаралары турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашырганда барлыкка килә торган Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына 2020 елда федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 ел, 4 июль, 980 нче карарын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын Татарстан Республикасының хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру мәсьәләләре буенча Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү федераль хезмәте белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы итеп билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасының хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Татарстан Республикасы бюджетына 2020 елда федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану тәртибен;

2020 елда эш бирүчегә эш эзләүче һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән гражданнар, шулай ук эшсез гражданнар; оешмаларның эштән азат итү рискында булган хезмәткәрләрен вакытлыча эшкә урнаштыру өчен җәмәгать эшләрен оештырганда өлешчә хезмәт өчен түләү чыгымнарын каплауга субсидия бирү тәртибен.

3. Бу карарны куллану буенча аңлатмалар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Бу карарның гамәле 2020 елның 7 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин